КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 1 март г.Казань № 108

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында халыкның аерым категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2004 ел, 17 декабрь, 542 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында халыкның аерым категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2004 ел, 17 декабрь, 542 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 22 гыйнвар, 22 нче; 2005 ел, 30 май, 239 нчы; 2006 ел, 2 октябрь, 490 нчы; 2007 ел, 6 апрель, 123 нче; 2008 ел, 8 сентябрь, 640 нчы; 2010 ел, 29 ноябрь, 956 нчы; 2011 ел, 21 июнь, 496 нчы; 2011 ел, 6 декабрь, 1001 нче; 2012 ел, 13 апрель, 304 нче; 2013 ел, 19 гыйнвар, 20 нче; 2013 ел, 12 март, 157 нче; 2014 ел, 8 февраль, 80 нче; 2014 ел, 5 декабрь, 947 нче; 2015 ел, 15 апрель, 254 нче; 2015 ел, 1 декабрь, 911 нче; 2016 ел, 22 июнь, 425 нче; 2017 ел, 10 май, 268 нче; 2017 ел, 28 август, 604 нче; 2017 ел, 27 октябрь, 812 нче; 2017 ел, 1 ноябрь, 833 нче; 2018 ел, 25 декабрь, 1228 нче; 2019 ел, 7 март, 163 нче; 2019 ел, 5 август, 644 нче; 2019 ел, 10 декабрь, 1131 нче; 2020 ел, 2 июнь, 461 нче; 2020 ел, 11 сентябрь, 827 нче;

2020 ел, 5 ноябрь, 999 нчы; 2020 ел, 16 декабрь, 1141 нче; 2021 ел, 12 июль, 567 нче; 2021 ел, 13 август, 713 нче; 2021 ел, 28 сентябрь, 918 нче; 2022 ел, 11 март, 214 нче; 2022 ел, 30 декабрь, 1479 нчы; 2023 ел, 3 март, 200 нче, 2023 ел, 16 октябрь, 1313 нче, 2024 ел, 1 февраль, 53 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Әлеге Нигезләмә «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын үтәү максатында эшләнде һәм түбәндәге адреслы социаль ярдәм күрсәтү чараларын бирү тәртибен билгели:

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән айлык акчалата түләүне (алга таба - айлык акчалата түләү);

6 яшькә кадәрге бала өчен дарулар сатып алуга субсидияләр;

гомуми белем бирү оешмалары укучыларына һәм һөнәри белем бирү оешмалары студентларына транспортта йөрүгә ай саен бирелә торган субсидия;

төп белем бирү программалары буенча белем алучы ятим балаларга, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларга һәм белем алу чорында ата-анасының икесен дә яисә бердәнбер ата-анасын югалткан затларга (алга таба - юл йөрүгә субсидия);

Татарстан Республикасы бюджеты яки җирле бюджетлар акчасы хисабыннан төп һөнәри белем бирү программалары буенча һәм (яисә) эшче һөнәрләре, хезмәткәрләр вазыйфалары буенча һөнәри әзерлек программалары буенча белем алуның көндезге формасында белем алучы ятим балаларга, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге затларга һәм белем алу чорында ике ата-анасын яисә бердәнбер ата-атасын югалткан затларга, Татарстан Республикасы бюджеты яки җирле бюджетлар акчасы хисабыннан төп гомуми, урта гомуми белем бирү программалары буенча белем алучы ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге затларга һәм белем алу чорында ике ата-анасын яисә бердәнбер ата-анасын югалткан затларга мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларны тәмамлаганда бер тапкыр бирелә торган пособие (алга таба - укуны тәмамлаганда бер тапкыр бирелә торган пособие);

Татарстан Республикасы бюджеты яки җирле бюджетлар акчасы хисабыннан төп һөнәри белем бирү программалары буенча һәм (яисә) эшче һөнәрләре, хезмәткәрләр вазыйфалары буенча һөнәри әзерлек программалары буенча белем алуның көндезге формасында белем алучы ятим балаларга, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге затларга һәм белем алу чорында ике ата-анасын яисә бердәнбер ата-атасын югалткан затларга, Татарстан Республикасы бюджеты яки җирле бюджетлар акчасы хисабыннан төп гомуми, урта гомуми белем бирү программалары буенча белем алучы ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар

исәбендәге затларга һәм белем алу чорында ике ата-анасын яисә бердәнбер ата-анасын югалткан затларга мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларны тәмамлаганда  кием-салым, аяк киеме комплекты  һәм йомшак инвентарь һәм җиһазлар  сатып алуга бер тапкыр бирелә торган пособие (алга таба - кием-салым, аяк киеме комплекты һәм йомшак инвентарь һәм җиһазлар сатып алуга бер тапкыр бирелә торган пособие);

Татарстан Республикасы бюджеты яки җирле бюджетлар акчасы хисабыннан төп һөнәри белем бирү программалары буенча һәм (яисә) эшче һөнәрләре, хезмәткәрләр вазыйфалары буенча һөнәри әзерлек программалары буенча белем алуның көндезге формасында белем алучы ятим балаларга, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге затларга һәм белем алу чорында ике ата-анасын яисә бердәнбер ата-атасын югалткан затларга, Т  Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән көндезге эшчеләрне һәм хезмәткәрләрне яңадан әзерләү программалары буенча көндезге бүлектә укучыларгаалучы сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән (шул исәптән акыл үсеше төрле формаларда арта калган) ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге затларга һәм белем алу чорында ике ата-анасын яисә бердәнбер ата-анасын югалткан затларга уку әдәбияты һәм язу әсбаплары сатып алуга еллык пособие (алга таба - уку әдәбиятын һәм язу әсбапларын сатып алуга еллык пособие);

Татарстан Республикасы бюджеты яки җирле бюджетлар акчасы хисабыннан төп һөнәри белем бирү программалары буенча һәм (яисә) эшче һөнәрләре, хезмәткәрләр вазыйфалары буенча һөнәри әзерлек программалары буенча белем алуның көндезге формасында белем алучы ятим балаларга, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге затларга һәм белем алу чорында ике ата-анасын яисә бердәнбер ата-атасын югалткан затларга, Татарстан Республикасы бюджеты яки  җирле бюджетлар акчасы хисабыннан төп гомуми, урта гомуми белем бирү программалары буенча белем алучы ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге затларга һәм белем алу чорында ике ата-анасын яисә бердәнбер ата-анасын югалткан затларга кием-салым, аяк киеме комрлекты  һәм йомшак инвентарь сатып алуга еллык пособие (алга таба - кием-салым, аяк киеме комплекты һәм йомшак инвентарь сатып алуга еллык пособие);

Татарстан Республикасы бюджеты яки җирле бюджетлар акчасы хисабыннан төп һөнәри белем бирү программалары буенча белем алуның көндезге формасында белем алучы ятим балаларга, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларга һәм белем алу чорында ата-анасының икесен дә яисә бердәнбер ата-анасын югалткан затларга, инвалид балаларга, инвалидларга ай саен түләнә торган стипендия (алга таба – ай саен түләнә торган стипендия);

Татарстан Республикасы бюджеты яки җирле бюджетлар акчасы хисабыннан төп һөнәри белем бирү программалары буенча һәм (яисә) эшче һөнәрләре, хезмәткәрләр вазыйфалары буенча һөнәри әзерлек программалары буенча белем алуның көндезге формасында белем алучы ятим балаларга, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган

балалар исәбендәге затларга һәм белем алу чорында ике ата-анасын яисә бердәнбер ата-атасын югалткан затларга, Татарстан Республикасы бюджеты яки җирле бюджетлар акчасы хисабыннан төп гомуми, урта гомуми белем бирү программалары буенча белем алучы ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге затларга һәм белем алу чорында ике ата-анасын яисә бердәнбер ата-анасын югалткан затларга туклануга айлык пособие (алга таба - туклануга айлык пособие);

«сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән (шул исәптән акыл үсеше төрле формаларда арта калган) ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан затларга Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән көндезге эшчеләрне һәм хезмәткәрләрне яңадан әзерләү программалары буенча көндезге бүлектә укучыларга айлык акчалата түләү (алга таба - айлык акчалата түләү);

абонентка даими файдалануга бирелгән теркәлгән телефон элемтәсе челтәренең абонент линиясе, радио, күмәк антенна өчен түләү чыгымнарын каплауга субсидияләр (алга таба - элемтә хезмәтләре күрсәтелүгә субсидия);

телефон куюга бәйле чыгымнарны каплау;

юл йөргән өчен айлык акчалата түләү.»;

2.2 пунктның алтынчы абзацына «әлеге Нигезләмәнең 2.1 пунктында күрсәтелгән гражданга» сүзләрен өстәргә;

4.4 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Бу Нигезләмәнең 4.1 пунктында күрсәтелгән гражданнар, аларның законлы вәкилләре яки алар тарафыннан шанычнамә нигезендә вәкаләт бирелгән затлар гариза белән мөрәҗәгать иткәндә шәхесне раслый торган документын күрсәтә һәм банкта яки башка кредит оешмасында ачылган шәхси счет реквизитларын әлеге Нигезләмәнең 4.1 пунктында күрсәтелгән гражданга тапшыра.»;

5.4 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Бу Нигезләмәнең 5.1 пунктында күрсәтелгән гражданнар, аларның законлы вәкилләре яки алар тарафыннан шанычнамә нигезендә вәкаләт бирелгән затлар гариза белән мөрәҗәгать иткәндә шәхесне раслый торган документын күрсәтә һәм банкта яки башка кредит оешмасында ачылган шәхси счет реквизитларын әлеге Нигезләмәнең 5.1 пунктында күрсәтелгән гражданга тапшыра.»;

6.2 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән (шул исәптән акыл үсеше төрле формаларда арта калган) ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан затларга Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән көндезге эшчеләрне һәм хезмәткәрләрне яңадан әзерләү программалары буенча көндезге бүлектә укучыларга.»;

түбәндәге эчтәлекле 6.41 пункт өстәргә:

«$6.4^1$. «Айлык пособие Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән көндезге эшчеләрне һәм хезмәткәрләрне яңадан әзерләү программалары буенча көндезге бүлектә укучы сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән (шул исәптән акыл үсеше төрле формаларда арта калган) ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан затларга билгеләнә һәм түләнә.»;

6.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.5. Транспортта йөрү өчен субсидия, укуны тәмамлаганда бер тапкыр бирелә торган акчалата пособие, укуны тәмамлаганда өс киеме, аяк киеме, йомшак инвентарь һәм җиһаз комплекты сатып алуга бер тапкыр бирелә торган пособие, уку әдәбиятын һәм язу кирәк-яраклары сатып алуга ел саен бирелә торган пособие, өс киеме, аяк киеме һәм йомшак инвентарь комплекты сатып алуга ел саен бирелә торган пособие, ай саен бирелә торган стипендия, туклануга ай саен бирелә торган пособие, шушы Нигезләмәнең 6.1 - 6.41 пунктларында күрсәтелгән гражданнар (алга таба - алучылар) ай саен бирелә торган пособие алу өчен аларны алучылар, аларның законлы вәкилләре яисә алар тарафыннан ышанычнамә нигезендә вәкаләт бирелгән затлар (алга таба – гариза бирүчеләр) белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешманың урнашу урыны буенча яисә опекунның (химаячενεң) яки алучының яшәү урыны буенча Үзәк бүлегенә, банкта яки башка кредит оешмасында ачылган шәхси счет реквизитларын (банк яки башка кредит оешмасы аша субсидияләр, стипендияләр, пособиеләр алганда) күрсәтеп, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан расланган форма буенча гариза тапшыра.

Укуны тәмамлаганда бер тапкыр бирелә торган пособие, укуны тәмамлаганда өс киеме, аяк киеме, йомшак инвентарь һәм җиһаз комплекты сатып алуга бер тапкыр бирелә торган пособие билгеләү турындагы гаризаны гариза бирүчеләр уку тәмамланган көннән 30 календарь көн эчендә белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешманың урнашу урыны буенча яисә опекунның (химаячененң) яки алучының яшәү урыны буенча Үзәк бүлегенә тапшыра.

Законлы вәкилләр (законнарда каралган очракларда) йә алучы тарафыннан вәкаләт бирелгән затлар аларның алучы мәнфәгатьләрен яклауга вәкаләтләрен раслый торган документлар күчермәләрен өстәмә рәвештә тапшыра.

Уку чорында атасы белән анасын яки ике бердәнбер атасын йә анасын югалткан затлар чит ил дәүләтенең компетентлы органы тарафыннан бирелгән ата-ананың үлеме турындагы документ күчермәсен һәм аның нотариаль таныкланган рус теленә тәрҗемәсе күчермәсен өстәмә рәвештә тапшыра.

Сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән (шул исәптән акылга зәгыйфьлегенең төрле рәвешләре белән) ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге затлар «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 42 статьясындагы 5 өлеше нигезендә төзелгән психологик-медицина-педагогик комиссия бәяләмәсенең күчермәсен тапшыра.

Документларның күчермәләре Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган очракта, алар төп нөсхәләре күрсәтелеп тапшырыла һәм Үзәк бүлеге белгече тарафыннан таныклана.

Гариза бирүчеләр гариза белән мөрәҗәгать иткәндә шәхесен таныклый торган документ күрсәтә.»;

6.8 пунктта «туклануга айлык пособие» сүзләреннән соң «, айлык пособие» сүзләрен өстәргә;

6.9 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән (шул исәптән акылга зәгыйфьлегенең төрле рәвешләре белән) ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган

балаларга, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге затларга уку әдәбияты һәм язу әсбаплары сатып алуга айлык пособие, еллык пособие эшчеләрне һәм хезмәткәрләрне яңадан әзерләү программалары буенча укырга керү аеннан башлап билгеләнә.»;

6.13 пунктта «6.4» саннарын «6.41» саннарына алмаштырырга;

6.14 пунктта «6.4» саннарын «6.41» саннарына алмаштырырга;

7.2 пунктның җиденче абзацына «әлеге Нигезләмәнең 7.1 пунктында күрсәтелгән гражданга» сүзләрен өстәргә;

8.2 пунктның җиденче абзацына «яисә реабилитацияләнгән гражданга башка кредит оешмасы» сүзләрен өстәргә;

9.1 пунктның тугызынчы абзацына «пенсионерга» сүзен өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин